**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

Россия Федерациясе Урман кодексының 83 статьясы һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге ФЗ-210 номерлы Федераль закон нигезендә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын күтәрү һәм аларны күрсәткәндә урман законнары үтәлүен тәэмин итү максатларында **карар бирәм**:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына әлеге Указ нигезендә расланган административ регламентка, законнарда каралган очракларда, билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне вакытында бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 11 декабрь
№ ПУ-1191

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның « 11 » декабрендәге
ПУ- 1191 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – дәүләт хезмәте) Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә административ процедураларның срокларын һәм эзлеклелеген, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартларын билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар булып гражданнар (алга таба – гариза бирүчеләр) санала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә.

1.4. Министрлык урнашкан урын: 420124, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Хөсәен Ямашев проспекты, 37а номерлы йорт.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, төшке аш: 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр.

Министрлыкның дәүләт урман реестры, урманнардан файдалану һәм урманга кагылышлы дәүләт чаралары бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: (843) 221-37-42, (843) 221-37-43.

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты: minleshoz.tatarstan.ru.

Министрлыкның электрон почта адресы: Minleshoz@tatar.ru/

1.5. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хакимияте органнары актларын өйрәнгәндә;

2) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге

мәгълүматлар кертелгән дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмати элмә такталар аша;

3) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында;

«Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (uslugi.tatar.ru);

«Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (gosuslugi.ru);

4) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефоннан);

5) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә кагылышлы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмати элмә такталарда урнаштырыла.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы: гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү.

2.2. Дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан күрсәтелә.

Гариза бирүчеләрдән дәүләт яки муниципаль хезмәтләрдән файдалану өчен һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән шундый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган хезмәтләрне һәм документларны һәм мәгълүматларны алудан кала, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларына мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.3. Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү яки гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәрнамә (хат) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып тора.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең гомуми вакыты – гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү турындагы гариза (алга таба – гариза) теркәлгән көннән соң 24 көнгә кадәр.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр түбәндәге норматив-хокукый актлар нигезендә җайга салына:

Россия Федерациясе Конституциясе (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1996, № 3, 152 ст.; № 7, 676 ст.; 2001, № 24, 2421 ст.; 2003, № 30, 3051 ст.; 2004, № 13, 1110 ст.; 2005, № 42, 4212 ст.; 2006, № 29, 3119 ст.; 2007, № 1, 1 ст.; № 30, 3745 ст.; 2009, № 1, 1, 2 ст.; № 4, 445 ст.; 2014, № 6, 548 ст.; № 30, 4202 ст.);

Россия Федерациясе Урман кодексы (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 50, 5278 ст.; 2008, № 20, 2251 ст.; № 30, 3597 ст., 3599; № 30, 3616 ст.; № 52, 6236 ст.; 2009, № 11, 1261 ст.; № 29, 3601 ст.; № 30, 3735 ст.; № 52, 6441 ст.; 2010, № 30, 3998 ст.; 2011, № 1, 54 ст.; № 25, 3530 ст.; № 27, 3880 ст.; № 29, 4291 ст.; № 30, 4590 ст.; № 48 6732 ст.; № 50, 7343 ст.; 2012, № 26, 3446 ст.; № 31, 4322 ст.; 2013, № 51, 6680 ст.; № 52, 6961 ст., 6971 ст., 6980 ст.; 2014, № 11, 1092 ст.; № 26, 3377 ст., 3386 ст.; № 30, 4251 ст.; 2015, № 27, 3997 ст.; № 29, 4350, 4359 ст.);

«Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 4 декабрендәге 201-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 50, 5279 ст.; 2007, № 31, 4014 ст.; 2008, № 20, 2251 ст.; № 30, 3597 ст., 3599; 2009, № 11, 1261 ст.; № 19, 2283 ст.; № 52, 6441 ст., 6455; 2011, № 1, 54 ст.; № 19, 2716 ст.; № 30, 4570 ст., 4590; № 49, 7043 ст.; № 51, 7448 ст.; 2012, № 27, 3587 ст.; 2013, № 23, 2866 ст.; № 49, 6343 ст.; 2014, № 26, 3377 ст.; 2015, № 1, 12 ст., 72 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст.; 2011, № 15, 2038 ст.; № 27, 3873 ст., 3880; № 29, 4291 ст.; № 30, 4587 ст.; № 49, 7061 ст.; 2012, № 31, 4322 ст.; 2013, № 14, 1651 ст.; № 27, 3477 ст., 3480; № 30, 4084 ст.; № 51, 6679 ст.; № 52, 6952 ст., 6961 ст., 7009 ст.; 2014, № 26, 3366 ст.; № 30, 4264 ст.; № 1, 67 ст., 72 ст.; № 10, 1393 ст.; № 29, 4342, 4376 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең дәүләт бюджетныкы булмаган фондлары вазыйфаи затларының, шулай ук атом энергиясе буенча «Росатом» дәүләт корпорациясенең һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр бирү һәм аларны карап тикшерү тәртибе хакында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2012, № 35, 4829 ст.; 2014, № 50, 7113 ст.; 2015, № 47, 6396 ст.);

Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының «Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен әзерләү һәм төзү тәртибен һәм Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләренең үрнәк формасын раслау турында» 2011 елның 26 июлендәге 318 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2011 елның 4 октябрендә теркәлгән, теркәлү номеры – 21972; Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2011, № 42; Российская газета, 2012, 29 июнь);

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12, (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш);

2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2015, 10 ноябрь);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 12 февралендәге 38 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2007, № 8; 2008, № 24; № 30; 2009, № 18, ; 2010, № 29; 2011, № 11; № 32; 2012, № 18-19; № 68; 2013, № 23; № 67; 2014, № 28; № 47-48; № 69; 2015, № 79).

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документ – формасы әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтада бирелгән гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гариза бирүче турында мәгълүмат – фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәгән урыны буенча теркәлүе турында белешмә, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре;

2) аның чикләрендә урман утыртмаларын сату-алу башкарылырга тиешле урманчылыкның (урман-паркның) атамасы;

3) үзагачның таләп ителгән күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм әзерләү максаты.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури дәүләт органнары карамагындагы һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокукы булган документлар исемлеге норматив хокукый актлар нигезендә каралмаган.

2.8. Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив-хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруны яки каралмаган гамәлләр кылуны;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру хакында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан кала, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары норматив-хокукый актлары һәм муниципаль норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарына караучы оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматларны.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап язылган гаризаны кабул итүдән баш тартуга түбәндәгеләр нигез була:

1) гаризада әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларның булмавы;

2) әлеге Административ регламентның 1.2 пункты нигезендә дәүләт хезмәтеннән файдаланучы була алмаган затның дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүе.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) үзагачның гаризада күрсәтелгән күләме «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нормативлардан артып китә;

2) граждан тарафыннан күрсәтелгән урманчылыкта (урман-паркта) гаризада күрсәтелгән күләмдә сыйфат күрсәткечләре тиешлечә булган үзагач әзерләү өчен җитәрлек торган урман утыртмалары булмау;

3) «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән сроклар үтәлмәү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган башка төр хезмәтләр күрсәтелми.

2.12. Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.

2.13. Гариза биргәндә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы нәтиҗә язылган кәгазьне алу өчен чират тору 15 минуттан да артмаска тиеш.

2.14. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап язган гаризаны теркәү гариза кергән көнне әлеге Административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә башкарыла.

2.15. Гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматтан торган элмә такталар урнаштырыла. Бинаның фасад өлешендә Министрлыкның атамасы турында мәгълүмат урнаштырыла.

Гариза бирүчеләргә кабул итүне көтеп алу һәм документларны рәсмиләштерү өчен өстәлләр, урындыклар белән җиһазландырылган урыннар бирелә.

Бүлмәләр санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш.

Министрлыкта инвалидларга хезмәт күрсәтү өчен шартлар тудыру зарур: биналар пандуслар, махсус киртәләр һәм култыксалар белән тәэмин ителергә тиеш.

Министрлык бинасына янәшә территориядә транспорт кую өчен урыннар корыла.

2.16. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре:

1) гаризаны кабул итү һәм карау сроклары үтәлү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;

3) Министрлыкның дәүләт хезмәткәрләре (эшчеләре) тарафыннан әлеге Административ регламент бозылуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу (Министрлыкның хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына карата прецендентлар, шикаятьләр санының нисбәте).

2.17. Гариза бирүченең Министрлыкның вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлеге түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) гариза тапшырганда – 15 минуттан да артык түгел;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда – 15 минуттан да артык түгел.

2.18. Дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турындагы мәгълүмат Министрлыкка телдән (шәхсән, вәкил яки телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан алынырга мөмкин.

2.19. Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен дәүләт яки муниципаль күпфункцияле хезмәтләр күрсәтү үзәгенә (алга таба – КФҮ) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә башкарыла.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен КФҮ аша документлар җиткерелгән очракта, процедуралар әлеге Административ регламент нигезендә башкарыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

2.21. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелми.

## III. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, башкару эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

### Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1. Әлеге бүлектәге административ процедураларның тулы исемлеге:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

гаризаны карау һәм гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе (алга таба – шартнамә) төзү турында яки төзүдән баш тарту турында карар проектын әзерләү;

шартнамә төзү яки төзүдән баш тарту турында карар кабул итү;

гариза бирүчегә шартнамә төзү яки төзүдән баш тарту турында хәбәр итү;

шартнамә төзү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән рәсми кәгазьләрдә җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтү.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү блок-схемасы әлеге Административ регламентка 2 нче кушымтада бирелгән.

### Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3. Административ процедура гариза бирүгә нигезләнеп башлап җибәрелә.

3.4. Административ процедураны башкару өчен җаваплы зат буларак Бүлекнең вәкаләт бирелгән белгече санала.

3.5. Гариза бирүче шәхсән яки вәкиле аша Министрлыкка яки КФҮ аша әлеге Административ регламентның 2.19 пункты нигезендә, әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтадагы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза тапшыра.

Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән булырга тиеш.

Электрон документ формасындагы гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (uslugi.tatar.ru) яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәй порталы (gosuslugi.ru) аша бирелә.

3.6. Министрлыкның оештыру эше бүлегенең вәкаләт бирелгән белгече:

1) гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булмаса:

а) гаризаны терки;

б) гариза бирүчегә, кабул итү датасын һәм теркәү номерын куеп, гаризаның күчермәсен тапшыра;

в) гаризаны Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрына (алга таба – министр) җибәрә;

2) гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гаризаны, баш тартуны нигезләп, гариза бирүчегә кайтарып бирә.

3.7. Әлеге Административ регламентның 3.6 пунктында каралган гамәлләр гариза кергән көнне башкарыла.

3.8. Теркәлгән, министрга җибәрелгән гариза административ процедураның нәтиҗәсе булып санала.

Гаризаны карау һәм шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту турында карар проекты әзерләү

3.9. Министрның теркәлгән гаризаны алуы административ процедураны башлауга нигез булып тора.

3.10. Административ процедураны башкару өчен җаваплы зат булып Бүлек башлыгы санала.

3.11. Министр гаризаны карап тикшерүне Бүлек башлыгына тапшыра.

3.12. Бүлек башлыгы гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләренә нигезләнеп:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, Министрлыкның шартнамә төзү турындагы боерыгы проектын әзерли һәм гаризаны һәм карар проектын Министрлыкка җибәрүне тәэмин итә;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Министрлыкның шартнамә төзүдән баш тарту турында боерыгы проектын

әзерли һәм гаризаны һәм карар проектын Министрлыкка җибәрүне тәэмин итә.

3.13. Әлеге Административ регламентның 3.11 һәм 3.12 пунктларында каралган гамәлләр гаризаны теркәгәннән соң сигез көн дәвамында башкарыла.

3.14. Гаризаны карап тикшерү һәм Министрлыкның шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту турында әзерләнгән хокукый акт проекты административ процедураның нәтиҗәсе була.

Шартнамә төзү яки төзүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.15. Гаризаны карап тикшерү һәм Министрлыкның шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту турында әзерләнгән хокукый акт проекты административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.16. Бүлек башлыгы административ процедураны башкару өчен җаваплы зат булып санала.

3.17. Бүлек белгече:

1) Министрлыкның шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту турындагы хокукый акт проектын имзалау өчен министрга бирә;

2) Министрлыкның шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту турындагы хокукый акты проектын теркәүне тәэмин итә.

3.18. Әлеге Административ регламентның 3.17 пунктында каралган гамәлләр гаризаны теркәгәннән соң 15 көннән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш.

3.19. Министрлык тарафыннан кабул ителгән шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту турында чыгарылган хокукый акт административ процедураның нәтиҗәсе була.

Гариза бирүчегә шартнамә төзү яки шартнамә төзүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү

3.20. Министрлык тарафыннан шартнамә төзү яки шартнамә төзүдән баш тарту турындагы боерык кабул ителгән административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.21. Бүлек башлыгы административ процедураны башкару өчен җаваплы зат булып санала.

3.22. Бүлекнең вәкаләтле белгече гариза бирүчегә кулга тапшырылу турындагы хәбәрнамә белән гариза бирүчегә Министрлык тарафыннан кабул ителгән карар турында хәбәрнамәне заказлы хат белән җибәрә. Шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хатта мондый баш тартуның сәбәбе күрсәтелә.

3.23. Әлеге Административ регламентның 3.22 пунктында каралган гамәлләр Министрлыкның шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту

турында хокукый акт басылып чыккан көннән соң биш көн дәвамында башкарыла.

3.24. Гариза бирүчегә шартнамә төзү яки аны төзүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү административ процедураның нәтиҗәсе була.

## Шартнамә төзү

3.25. Министрлыкның шартнамә төзү турындагы хокукый акты административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.26. Бүлек башлыгы процедураны башкару өчен җаваплы зат булып санала.

3.27. Бүлек белгече:

1) өч нөсхәдә шартнамә проектын әзерли;

2) имза салу өчен шартнамәне министрга һәм гариза бирүчегә тапшыра;

3) шартнамәне теркәүне һәм аның бер нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыруны тәэмин итә.

3.28. Әлеге Административ регламентның 3.27 пунктында каралган гамәлләр Министрлыкның шартнамә төзү турында хокукый акты басылып чыккан көннән алып 10 көн дәвамында башкарыла.

3.29. Шартнамә төзү административ процедураның нәтиҗәсе булып санала.

## Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм (яки) ялгышлыкларны төзәтү

3.30. Гариза бирүче тарафыннан алынган шартнамәдә яисә шартнамә төзүдән баш тарту турында белдерү кәгазендә басмадагы хаталар һәм (яки) ялгышлыклар табылган очракта, гариза бирүче Министрлыкка мондый басмадагы хаталарны һәм (яки) ялгышлыкларны төзәтү турында гариза тапшыра.

3.31. Бүлекнең вәкаләтле белгече тиешле гаризаны теркәгән көннән соң ике эш көненнән артмаган вакыт эчендә гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерү үткәрә.

3.32. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы хаталар һәм (яки) ялгышлыклар табылган очракта, Бүлекнең вәкаләтле белгече тиешле гаризаны теркәгән көннән соң биш эш көненнән артмаган вакыт эчендә аларны алыштыра.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту формалары

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр

билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы булган зат яки дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән башкарыла.

Агымдагы контроль даими нигездә башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүдән, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очракларын ачыклау һәм бетерүдән, гариза бирүчеләрнең Министрлыкның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләре кертелгән мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүдән, алар буенча карарлар кабул итүдән һәм җаваплар әзерләүдән тора.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү Министрлык актлары нигезендә башкарыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш була ала.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның таләпләре бозылуның элегрәк ачыкланган очракларын бетерүне тикшерү белән бәйле рәвештә;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмаулары) сәбәпле гражданнар үзләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында шикаять белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Контрольдә тоту нәтиҗәләре буенча гариза бирүче хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелүне гариза бирүчеләр тарафыннан контрольдә тоту әлеге Административ регламентта каралган мәгълүматны алу юлы белән, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затның гамәлләрен (гамәл кылмауларын), аның тарафыннан кабул ителә торган карарга шикаять бирү юлы белән башкарыла.

## V. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә башкарыла торган һәм әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның таләпләрен боза торган гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукына ия.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, яисә дәүләт граждан хезмәткәренең гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм алар тарафыннан кабул ителгән (башкарыла торган) карарлар судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу предметы булып тора.

Гариза бирүче шикаять бирә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәүгә бирелгән вакытка сыешмаганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бирелгән вакытка сыешмаганда;

3) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, әлеге Административ регламентта каралмаган документларны тапшыру таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларны тапшыру Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, әлеге Административ регламентта каралган булса, документларны кабул итүдән баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр дә баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка төрле Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, әлеге Административ регламентта каралмаган түләүне кертү таләп ителсә;

7) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләр өчен билгеләнгән вакытка сыешмавы.

5.3. Шикаять Министрлыкка бирелә. Министр тарафыннан кабул ителгән карарга шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.4. Шикаять язма рәвештә, яки мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә, яки электрон рәвештә бирелә.

5.5. Шикаять гариза бирүче вәкиле аша тапшырылганда, аның гариза бирүче исеменнән гамәл кылырга вәкаләтләре барлыгын раслый торган документ та тапшырыла. Мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылырга

вәкаләтләре барлыгын раслый торган документ сыйфатында Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә тапшырылырга мөмкин.

5.6. Язма рәвештә бирелгән шикаятьне кабул итү Министрлык тарафыннан эш вакытында башкарыла.

Язма рәвештә бирелгән шикаять шулай ук почта аша да җибәрергә мөмкин.

Шикаятьне шәхсән кабул итү барышында тапшырганда, гариза бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенең шәхесен таныклый торган документны күрсәтә.

5.7. Электрон рәвештә бирелүче шикаять гариза бирүче тарафыннан түбәндәгеләр ярдәмендә тапшырылырга мөмкин:

1) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайты;

2) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы;

3) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы;

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан «Интернет» челтәреннән файдаланып дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә чыгарылган карарларына һәм кылынган гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы.

5.8. Шикаятьне электрон рәвештә тапшырган очракта, әлеге Административ регламентның 5.5 пунктында күрсәтелгән документлар электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин, аның рәвеше Россия Федерациясе законнарында каралган, шул ук вакытта гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документ таләп ителми.

5.9. Шикаять мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылырга мөмкин. Шикаять кергәндә, КФҮ, КФҮ белән Министрлык арасындагы хезмәттәшлек шартнамәсендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта, ләкин шикаять кергән көннән соң килүче эш көннән дә соңга калмыйча, аны карап тикшерү өчен вәкаләтле органга тапшыруны тәэмин итә.

5.10. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) Министрлыкның атамасы, Министрлыкның карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять кылынучы тиешле вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме яки вазыйфасы;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, элемтә өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яисә дәүләт граждан хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) ризасызлыгына нигез булган дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан үз дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта), яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.11. Министрлыкка тапшырылган шикаять, кергән көненнән соң килүче эш көннән дә соңга калмыйча, теркәлә һәм шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан, теркәлгән көненнән алып 15 эш көне эчендә, әгәр дә Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гариза бирүченең документларын кабул итүдән яисә басмадагы хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтүдән баш тартуына шикаять бирелгәндә яисә гариза бирүче мондый төзәтмәләрне кертүнең билгеләнгән вакытларына сыймауга карата шикаять биргәндә – теркәлгән көненнән алып, биш эш көне дәвамында карап тикшерелергә тиеш.

5.12. Шикаятьне карап тикшерүне туктату өчен нигезләр юк.

5.13. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык акт рәвешендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү турында, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтү, гариза бирүчегә аларны алу норматив-хокукый актларда каралмаган акчаларны кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка төрле рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында.

5.14. Әлеге Административ регламентның 5.13 пунктында күрсәтелгән карарны кабул итү көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.15. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 5.63 статьясында каралган административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, әлеге Административ регламентның 5.3 пункты нигезендә шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, кичекмәстән, булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

5.16. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән җавапта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) дәүләт хезмәтен күрсәткән, шикаятьне карап тикшергән органның исеме, шикаять буенча карар кабул иткән вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) карарына яки гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган вазыйфаи зат турындагы мәгълүматларны да кертеп, карарның номеры, датасы, кабул ителгән урыны;

3) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

4) шикаять буенча карар кабул итү өчен нигезләр;

5) шикаять буенча кабул ителгән карар;

6) шикаять нигезле дип табылган очракта, ачыкланган хокук бозуларны бетерү сроклары, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү срогы;

7) шикаять буенча кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүматлар.

5.17. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән җавапка шикаятьне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат имза куя.

5.18. Гариза бирүче шикаятьне карап тикшерү барышында Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән карардан риза булмаган очракта, яки алар тарафыннан карар кабул ителмәсә, гариза бирүче Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать итәргә яки кабул ителгән карарга суд аша Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

5.19. Гариза бирүче шикаятьне дәлилләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүматны һәм документларны алу хокукына ия.

5.20. Шикаятьне бирү һәм карап тикшерү тәртибе турындагы мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга була:

1) Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарында урнаштырылган, шикаятьне бирү һәм карап тикшерү тәртибе турында визуаль һәм текст рәвешендә мәгълүматлар булган мәгълүмати элмә такталардан;

2) «Интернет» челтәреннән:

Министрлыкның рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында;

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында;

3) Министрлыкка телдән (телефон аша яки шәхсән) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

5.21. Министрлык шикаятьне канәгатьләндерүдән түбәндәге очракларда баш тарта:

1) шул ук предмет һәм шул ук нигезләр буенча шикаятькә карата законлы көченә кергән суд карары булу;

2) шикаятьнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләре расланмаган зат тарафыннан бирелүе;

3) шул ук гариза бирүчегә карата һәм шикаятьтәге шул ук предметка карата элегрәк кабул ителгән карар булу.

5.23. Министрлык түбәндәге очракларда шикаятьне җавапсыз калдыра (бу хакта гариза бирүчегә билгеләнгән тәртиптә хәбәр итә):

1) шикаятьтә цензурасыз яки мыскыллы гыйбарәләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә янаулар булу;

2) шикаять текстын, мөрәҗәгать итүченең фамилиясен яки почта адресын уку мөмкинлеге булмау.

Татарстан Республикасы
территориясендә гражданнарның
шәхси ихтыяҗлары өчен урман
утыртмаларын сату-алу
шартнамәләре төзү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
урман хуҗалыгы министрына

______________________________________
(Ф.И.А.и.)
кемнән________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и.), яшәгән
______________________________________
урынында теркәлү турында белешмәләр, шәхесен
______________________________________
таныклый торган документлар белешмәләре

Гариза

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Сездән________________________________урманчылыгы чикләрендә, _______куб.метр күләмендә ______________________________
(токым составы, эшкәртүгә яраклы, утынлык)
____________ сыйфат күрсәткечле үзагачны ____________________________
(үзагачны ни өчен алуны күрсәтергә)

гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында карар кабул итүегезне сорыйм.

______________________
(имза)

______________________
(дата)

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең
блок-схемасы

Гаризаларны кабул итү һәм теркәү

Гаризаны карап тикшерү һәм гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү яки аны төзүдән баш тарту турында карар кабул итү

Шартнамә төзү турында яки аны төзүдән баш тарту турында карар проекты әзерләү

Шартнамә төзү турында карар кабул ителү хакында гариза бирүчегә хәбәр итү

Шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул ителү хакында гариза бирүчегә хәбәр итү

Шәхси ихтыяҗлар өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү